| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СТАРОТЯБЕРДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ТЭРБИТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.08.2022 Иске Тэрбит ав. № 8

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы ИСКЕ ТЭРБИТ авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибен һәм срокларын раслау турында

Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына идарә органнарына, җирле үзидарә органнарына, җирле администрация органнарына бюджет керемнәренең баш администраторын беркетүгә гомуми таләпләрнең 10 пункты һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына идарә органнарына, җирле үзидарә органнарына, бюджет керемнәренең баш администраторы вәкаләтләрен җирле администрация органнарына беркетүгә һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты, территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслауга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2021 елның 16 сентябрендәге 1569 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе субъекты бюджеты, территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты, җирле бюджет керемнәренең баш администраторлары исемлеге нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске Тэрбит авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тэрбит авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибен һәм срокларын кушымтада каралганча расларга.
2. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2022 елның 01 августыннан барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске Тэрбит авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Иске Тэрбит авыл җирлеге Башкарма комитеты
Җитәкчесе В.Г.Тимофеев

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Кошман авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2022 елның 01 августындагы
8 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тэрбит авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибен һәм сроклары

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына идарә органнарына, җирле үзидарә органнарына, җирле администрация органнарына бюджет керемнәренең баш администраторын беркетүгә гомуми таләпләрнең 10 пункты һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына идарә органнарына, җирле үзидарә органнарына, бюджет керемнәренең баш администраторы вәкаләтләрен җирле администрация органнарына беркетүгә һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты, территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслауга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2021 елның 16 сентябрендәге 1569 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе субъекты бюджеты, территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты, җирле бюджет керемнәренең баш администраторлары исемлеге нигезендә эшләнгән һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске Тэрбит авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү механизмын һәм срокларын билгели (алга таба - исемлек, баш администратор).

2. Төп администраторларның составы һәм (яисә) функцияләре үзгәргән, шулай ук Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тэрбит авыл җирлеге бюджеты керемнәре классификациясе кодлары структурасын билгеләү һәм бирү принципларын үзгәртү, исемлеккә үзгәрешләр, шулай ук Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тэрбит авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторларына беркетелгән исемлеккә үзгәрешләр кертелгәндә «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске Тэрбит авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары һәм төп администраторлары исемлеген раслау турында» Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске Тэрбит авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына Финанс-бюджет палатасы приказы нигезендә кертелә.

3. Исемлеккә үзгәрешләр федераль һәм региональ законнарга бюджет керемнәре классификациясенең төп администраторларына беркетелгән кодлары составында үзгәреш өлешендә үзгәрешләр кертелүгә карап кертелә.